ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.10.2025 г. Агрыз № 94

## Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында "Россия Федерациясендә пробация турында"гы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында

«Россия Федерациясендә пробация турында»гы 2023 елның 6 февралендә кабул ителгән 10-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә пробация турындагы «Федераль закон нигезләмәләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру турында»гы 2019 елның 29 июлендә кабул ителгән 631 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзергә.
2. «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru)
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Муниципаль район Башлыгы Л. Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башлыгының
20.10 2025 елның 94 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**«Россия Федерациясендә пробация турында»гы Федераль закон нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әгерҗе муниципаль районы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында»гы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба - муниципаль комиссия) - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы каршында Даими эшләүче координацияләү органы, ул Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары белән, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм күрсәтелгән муниципаль берәмлектә эшчәнлек алып баручы башка оешмалар арасында пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлекне тәэмин итә.

1.2. Муниципаль комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә пробация турында»гы 2023 елның 6 февралендә кабул ителгән 10-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 29 июлендә кабул ителгән 631нче номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында»гы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында"гы нигезләмәне Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эш төркеме Нигезләмәсенә таяна.

1.3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалар белән пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

## II. Муниципаль комиссиянең төп бурычлары

Муниципаль комиссиянең төп бурычлары булып санала:

2.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында хөкем ителгәннәргә, җинаять-хокукый характердагы башка чаралар билгеләнгән затларга һәм мәҗбүри эшләр яисә ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән, авыр тормыш хәлендә калган затларга карата кулланыла торган чаралар комплексын гамәлгә ашыру, шул исәптән:

һөнәри ориентация һәм хезмәткә яраклашу;

Яшәү урынына һәм көнкүрештә урнаштыру;

медицина ярдәме күрсәтү;

белем алу;

социаль хезмәт күрсәтүгә хокукны гамәлгә ашыру;

психологик ярдәм;

юридик ярдәм;

югалган социаль элемтәләрне һәм функцияләрне торгызуга ярдәм итү; пробация кулланыла торган затларны ресоциализацияләүнең, социаль адаптацияләүнең һәм социаль реабилитацияләүнең башка формалары.

2.2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү, шул исәптән вакытлыча тору урыны бирү мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияләүне һәм үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү, пробация үзеген булдыру

2.3. Пробация кулланыла торган затларның бердәм реестрының муниципаль сегментын алып бару.

2.4. Кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау.

2.5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү буенча алып барыла торган эшләр турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү.

## III. Муниципаль комиссиянең вәкаләтләре

Муниципаль комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.1. Ресоциализацияләүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль реабилитацияләүдә ярдәм күрсәтү турында гариза биргән затларның социаль хәлен индивидуаль тәртиптә карый һәм анализлый.

3.2. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә, ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль реабилитация буенча индивидуаль программа нигезләмәләрен куллануны тикшерә һәм анализлый.

3.3. Әгерҗе муниципаль районында кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча

тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазыйфаи затларга җибәрә.

3.4. Муниципаль комиссия вәкаләтләре кысаларында:

3.4.1. Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, гражданлык җәмгыятенең башка оешмалары һәм институтлары тарафыннан үтәүгә тәкъдим ителгән карарларны үз компетенциясе чикләрендә кабул итә;

3.4.2. Җинаятькә яисә административ җаваплылыкка китерә торган закон бозу билгеләре ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне хәл итү өчен, хокук саклау органнарына тиешле документлар һәм материаллар җибәрә.

3.5. Муниципаль комиссия пробация өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен үз компетенциясе чикләрендә пробация субъектлары булган органнар, учреждениеләр һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итә:

3.5.1. Россия Федерациясе җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (аның территориаль бүлекчәләре) белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

пробация кулланыла торган хөкем ителгәннәрнең, җинаять-хокукый характердагы башка чаралар билгеләнгән затларның һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтүче яки иректән мәхрүм итү учреждениеләрдән азат ителгән һәм авыр тормыш хәлендә калган затларның, бердәм реестры операторы буларак исәпкә алу;

башкарма һәм постпенитенциар пробация кулланыла торган затлар белән социаль һәм тәрбияви эшләр уздыру;

ресоциальләштерүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль тернәкләндерүгә индивидуаль мохтаҗлыкны бәяләүне уздыру;

башкарма яки постпенитенциар пробация куллану турында карарлар кабул ителгән затлар өчен индивидуаль программалар әзерләү;

коммерциячел булмаган, шул исәптән дини, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан пробация үзәге эшчәнлеген оештыру;

3.5.2. Эчке эшләр органнары белән:

ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

башкарма һәм постпенитенциар пробация куллану;

индивидуаль профилактика эше уздыру;

хокукый белемнәрне пропагандалауда катнашу;

Россия Федерациясе гражданы паспорты белән хөкем ителгәнне документлаштыру;

3.5.3. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләр, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

мәҗбүри эшләр яисә ирегеннән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаны үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм авыр тормыш хәлендә калган затларга халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау (хезмәт күрсәтү) өлкәсендә,

шул исәптән социаль хезмәтләр күрсәтү һәм эшкә урнашуга ярдәм итү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

мәҗбүри эшләр яисә ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм авыр тормыш хәлендә калган затларга карата хезмәткә урнаштыру һәм социаль хезмәтләр күрсәтү буенча статистик мәгълүматны исәпкә алу;

социаль адаптация үзәкләрендә ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасыннан социаль хезмәт күрсәтүләрне алучылар белән, билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен профилактик эш;

социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче балигъ булмаганнарны, шулай ук ирегеннән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән балигъ булмаган гражданнарны социаль адаптацияләү;

пробация кулланыла торган затларны ресоциализацияләүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль реабилитацияләүгә буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында, хезмәт шартлары турында, хезмәт хакы һәм вакансияләр эзләүчеләргә квалификация таләпләре турында мәгълүмат бирү юлы белән ярдәм итү,;

ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга һөнәри юнәлеш буенча эшчәнлек өлкәсен (һөнәрне) сайлау буенча, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган категориядәге затларга һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү максатларында бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, социаль адаптацияләү буенча бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәннәргә эш бирүче, эшкә урнаштыручы затларны (работодателей) стимуллаштыру;

3.5.4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү, профилактик һәм диспансер күзәтүне оештыру мәсьәләләре буенча;

3.5.5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән гомуми белем, урта һөнәри белем алу, һөнәри белем алу мәсьәләләре буенча;

3.5.6. Россия Федерациясе Социаль фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге белән Индивидуаль лицевой счет ачу һәм индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәп системасында теркәлүне раслый торган һәм индивидуаль лицевой счетның иминият номеры турында белешмәләре булган документны рәсмиләштерү мәсьәләләре буенча, пенсия белән тәэмин итү буенча (аны алу хокукына ия затлар өчен);

3.5.7. Дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары, гражданлык җәмгыяте оешмалары, институтлары белән аларның компетенцияләре нигезендә.

## IV. Муниципаль комиссияне төзү тәртибе

4.1. Муниципаль комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

Муниципаль комиссия рәисе:

муниципаль комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

хәлиткеч тавыш хокукына ия булып, муниципаль комиссия утырышларын алып бара;

муниципаль комиссия утырышының көн тәртибен раслый;

ведомствоара комиссия әгъзаларына үз вәкаләтләре кысаларында йөкләмәләр бирә;

муниципаль комиссия кабул итә торган документларга имза сала;

муниципаль комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Муниципаль комиссия рәисе урынбасары:

комиссия рәисе кушуы буенча, ул булмаганда, муниципаль комиссия рәисе вазыйфаларын башкара;

муниципаль комиссия карарларының үтәлешен контрольдә тота;

ведомствоара информацион эшчәнлекнең тотрыклылыгын арттыру чараларын планлаштыру һәм гамәлгә ашыру эшчәнлеген оештыра;

Муниципаль комиссия секретаре:

муниципаль комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

муниципаль комиссия утырышының көн тәртибен төзи, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карар проектларын әзерләү эшен координацияли, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

муниципаль комиссия әгъзаларына һәм утырышка чакырылган затларга муниципаль комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат бирә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җәзаны үтәү системасы учреждениеләре администрацияләреннән килгән якын киләчәктә азат ителүче зат турында, аның торагы булу-булмавы, хезмәткә сәләте һәм булган белгечлекләре турында мәгълүмат җыюны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра;

Һәрбер иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның документлары, индивидуаль программа чараларының үтәлеше турында белешмәләр кергән ресоциализацияләү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү буенча картасын, шәхси эшен булдыра;

«Пробация кулланыла торган затларның бердәм реестры» дәүләт мәгълүмат системасының муниципаль сегментын алып бара;

муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан муниципаль комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматны соратып ала;

Ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

утырыш нәтиҗәләре буенча муниципаль комиссия рәисе йөкләмәләрен үтәүне оештыра;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы халкына муниципаль комиссиянең функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Муниципаль комиссия составы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгының боерыгы белән раслана.

4.3. Муниципаль комиссия составына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау оешмалары, мәгариф оешмалары вәкилләре керә (килешү буенча).

4.4. Муниципаль комиссия элек иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, ресоциализацияләүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль реабилитацияләүдә уңай тәҗрибәсе булган затларның практикасын анализлый һәм гомумиләштерә.

4.5. Муниципаль комиссия утырышларында Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасы вәкиле гамәлдәге законнар нигезендә катнашырга хокуклы.

4.6. Муниципаль комиссия утырышларына муниципаль комиссия составына керми торган дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмалар, гражданлык җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырыла.

4.7. Муниципаль комиссия эшендә катнашу иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашырыла.

V. Муниципаль комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Муниципаль комиссия эше даими нигездә башкарыла.

5.2. Муниципаль комиссия утырышлары иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциализацияләүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль реабилитацияләүгә ярдәм күрсәтү турында гаризалар кергән саен үткәрелә, әмма елына бер тапкырдан да сирәгрәк түгел. Муниципаль комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук муниципаль комиссия әгъзасы инициативасы белән (Рәис белән килештереп һәм муниципаль комиссия секретаре тәкъдиме буенча) муниципаль комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелә.

5.3. Муниципаль комиссия утырышларын муниципаль комиссия рәисе, ә ул булмаганда яисә аның кушуы буенча, муниципаль комиссия рәисе урынбасары алып бара.

5.4. Муниципаль комиссия утырышы, комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була.

5.5. Муниципаль комиссия карарлары тәкъдим итү характерында була һәм ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

5.6. Утырышларда карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда муниципаль комиссия әгъзалары тигез хокукларга ия булалар.

5.7. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затның теләге буенча утырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча уздырыла.

5.8. Муниципаль комиссия әгъзалары комиссия утырышында каралган мәсьәләләр турындагы белешмәләрне күрсәтелгән мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка таратмаска тиеш.

Гражданнарның щәхси тормышы турындагы белешмәләрне тараткан өчен муниципаль комиссия әгъзалары закон нигезендә җаваплы булалар.

5.9. Муниципаль комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатларында муниципаль комиссия рәисе рөхсәте белән массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүмат шәхси белешмәләрне күрсәтмичә бирелә.